**СОВЕТ**
**Кудашевского сельского поселения**
**Агрызского муниципального района**
**Республики Татарстан**

**Татарстан Республикасы**
**Әгерҗе муниципаль районы**
**Кодаш авыл җирлеге**
**СОВЕТЫ**

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

22.02.2024 Кодаш авылы № 37-1

«Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кодаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында» Әгерҗе муниципаль районының 26.11.2019 елның 53-2 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе Бюджет кодексының 96.6 һәм 220.1 статьяларына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында, Россия Федерациясе Бюджет кодексының аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору һәм 2024 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларын үтәү үзенчәлекләрен билгеләү турында» 2023 елның 2 ноябрендәге 520-ФЗ номерлы Федераль законнары нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кодаш авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1. «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Кодаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турындагы нигезләмәне раслау хакында» Әгерҗе муниципаль районының 26.11.2019 елның 53-2 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

а) 23 статьяның 3 пункты, 26 статьяның 3 пункты гамәлдә булуын 2024 елның 1 гыйнварыннан 2025 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының веб-адрес буенча хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының веб-адрес буенча портал составында Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: https://agryz.tatarstan.ru, шулай ук Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Кодаш авыл җирлеге җирле үзидарә органнары территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Совет Рәисе,
Авыл җирлеге башлыгы Ф.М.Шакиров